| СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ БУРНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.07.2018 с. Татарское Бурнашево № 48-210

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставы проекты турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегендә 2016 елның 16 декабрендәге 17-79 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә

Югары ослан муниципаль районы
Бурнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге башлыгы тәкъдим иткән Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге уставы проекты буенча түбәндәге составта тәкъдимнәр кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эш төркеме төзергә:

- эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы С.В. Бурукин;

- эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Р.А. Ильичева

Эшче төркем әгъзалары:

- С.М. Бочков - 1 нче Татар Борнашы сайлау округы депутаты;

С.И. Андреева - 4 нче Татар Борнашы сайлау округы депутаты;

В.А. Молькова - 6 нчы Татар Борнашы сайлау округы депутаты.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Бурнаш авыл җирлеге Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Уставы проекты буенча халык алдында тыңлауларны 13.08.2018 елда 15.00 сәгатьтә Борнаш авыл җирлеге башкарма комитеты бинасында, Татар Бурнашы авылы, Совет ур., 62 й. адресы буенча үткәрергә.

6. Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Борнаш авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Бурнаш авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районының
Бурнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин